| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2024 ел Баулы шәһәре №167

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 августындагы 169 номерлы (2023 елның 15 февралендәге 37 номерлы, 2024 елның 12 февралендәге 17 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 112 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары белән расланган, муниципаль милектә булган, җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы Административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнары, Законом Республики Татарстан от 28.07.2004 №45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 августындагы 169 номерлы (2023 елның 15 февралендәге 37 номерлы, 2024 елның 12 февралендәге 17 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 112 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары белән расланган, муниципаль милектә булган, җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3 кисәктә «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым

категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, үз эченә алган вариантлары»:

3.3.3.4. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.4.5. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.4.4., 3.4.5., 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның милли пространство белешмәләренең эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.5.4. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«әлеге административ регламентның 3.5.2- 3.5.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның милли пространство белешмәләренең эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.6.2. пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында милли пространство белешмәләренең эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л.Бакиров